БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» 08 2022 ел № 232

Хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Урманнарны яңадан торгызу һәм урман үстерү чараларына җәлеп ителгән халык саны, мең кеше» дәрәҗәсен бәяләүгә керә торган күрсәткечләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлегe регламентын раслау турында

«2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указлары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта итеп бирелгән Хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Урманнарны яңадан торгызу һәм урман үстерү чараларына җәлеп ителгән халык саны, мең кеше» дәрәҗәсен бәяләүгә керә торган күрсәткечләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3 . Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2022 елның «03» 08
232 номерлы карарына
кушымта

Балтач муниципаль районы буенча «Әйләнә-тирә мохит сыйфаты» Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләүнең федераль күрсәткеченең муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Урманнарны яңадан торгызу һәм урман үстерү чараларына җәлеп ителгән халык саны, мең кеше» ярдәмче күрсәткечен җыю һәм мониторинглау регламенты

## I. Гомуми нигезләмәләр

«Әйләнә-тирә мохит сыйфаты» Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү федераль күрсәткеченең муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Урманнарны яңадан торгызу һәм урман үстерү чараларына җәлеп ителгән халык саны, мең кеше» ярдәмче күрсәткечен җыю һәм мониторинглау регламенты (алга таба - Регламент) «Әйләнә-тирә мохит сыйфаты» Татарстан Республикасының Балтач муниципаль районы буенча югары вазыйфаи заты эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләүнең федераль күрсәткече (алга таба - Регламент) «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 4 июнендәге 1024 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 елның 31 декабрендәге 920 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең

бердәм ведомствоара системасы «Контроль» модуленең эшләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 18 апрелендәге 361 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнгән һәм «Әйләнә-тирә мохит сыйфаты» Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү федераль күрсәткеченең муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Урманнарны яңадан торгызу һәм урман үстерү чараларына җәлеп ителгән халык саны, мең кеше» ярдәмче күрсәткече (алга таба - Ярдәмче күрсәткече) зурлыкларын җыю тәртибен билгели.

Урманнарны яңадан торгызу һәм урман үстерү чараларын үткәрүне координацияләүче булып Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты тора. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты билгеләнгән тәртиптә оештыру чараларын һәм урманнарны яңадан торгызу һәм урман үстерү буенча чараларда катнашучыларның куркынычсызлыгын тәэмин итә.

Балтач муниципаль районында Ярдәмче күрсәткеч зурлыкларын мониторинглау өчен җаваплылык үзәге булып Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты тора.

Балтач муниципаль районында Ярдәмче күрсәткеч зурлыкларын җыю өчен җаваплылык үзәге булып Балтач муниципаль районы чикләрендә урнашкан «Урманчылык» ДКУ (алга таба - «Урманчылык» ДКУ) тора.

Ярдәмче күрсәткеч зурлыклары турында мәгълүмат җиткерүчеләр булып юридик һәм физик затлар - табигатьне саклау чараларында катнашучылар тора. Ярдәмче күрсәткеч зурлыклары турында мәгълүмат бирү формасы Регламентның кушымтасына туры килергә тиеш. Алына торган һәм тапшырыла торган мәгълүмат “Урманчылык” ДКУ җитәкче-урманчысы боерыгы белән билгеләнгән җаваплы зат тарафыннан архивлана.

“Урманчылык” ДКУ муниципаль район буенча берләштерелгән (агрегацияләнгән) мәгълүматны Балтач район башкарма комитетына кәгазь күчермәдә яисә электрон рәвештә җибәрә.

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты, __________________ мәгълүмат системасын кулланып, берләштерелгән (агрегацияләнгән) мәгълүматны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына (алга таба - Министрлык) җибәрә.

## II. Төшенчә аппараты

Регламентта түбәндәге терминнар һәм аларның билгеләмәләре кулланыла.

Урманнарны яңадан торгызу - урман фонды территориясендә яңа урман утыртмалары булдыру һәм формалаштыру чаралары

Урман үстерү - элек урман утыртмалары булмаган җирләрдә яңа урман утыртмалары булдыру чарасы

Урманнарны яңадан торгызу һәм урман үстерү чараларына җәлеп ителгән халык - агач утыртуда һәм табигатьне саклау буенча башка акцияләрдә катнашучы физик затлар һәм/яки юридик затларның хезмәткәрләре.

Инициатив мәгълүмат - урманнарны яңадан торгызу һәм урман үстерү чараларында катнашучы яисә катнашырга планлаштыручы инициатив төркем тарафыннан тапшырыла торган мәгълүмат

## III. Мәгълүмат җыю тәртибе, аны бирү вакытлары һәм формалары

Урманнарны яңадан торгызу һәм урман үстерү чаралары түбәндәгечә үткәрелергә мөмкин:

- оешкан формада урманнарны яңадан торгызу һәм урман үстерү чараларын яисә югары хакимият органнары һәм/яисә оешмаларның оештыручылары, коммерция оешмаларының идарә органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нигезендә, алдан әзерләнгән план буенча яисә оператив рәвештә;

- инициатив тәртиптә, иҗтимагый оешмалар, социаль учреждениеләр, җирлекләрнең җирле үзидарә органнары, торак пунктларда яшәүчеләрнең инициатив төркемнәре, предприятиеләр һәм оешмалар үткәрә.

Урманнарны яңадан торгызу һәм урман үстерү чараларының беренче категориясе урман фонды территориясендә уздырыла. Кагыйдә буларак, бу урманчылар билгеләгән урыннарда агач утырту чаралары. Яңадан җитештерү һәм урман үстерү чараларын үткәрү планы (алга таба - План) Министрлык тарафыннан төзелә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы белән килештерелә. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты Планга туры китереп яңадан торгызу һәм урман үстерү буенча чаралар үткәрү графигын төзи һәм күрсәтелгән график нигезендә чараларда катнашучыларны чакыра.

Чараларның икенче категориясе - Балтач муниципаль районы территориясендә уздырыла торган урманнарны яңадан торгызу һәм урман үстерү чаралары. Мондый чаралар мониторингы формальләштерелмәгән

булганга, ә алар биләгән халык саны шактый зур булу сәбәпле, санап үтелгән субъектлар өчен мөлкәти, мәгълүмати, кадрлар, финанс формалары рәвешендәге муниципаль ярдәм чаралары каралырга мөмкин. Мондый чаралар исемлеге республика яисә муниципаль дәрәҗәдәге хакимиятнең тиешле органы тарафыннан билгеләнә. Шул ук вакытта җирле дәрәҗәдәге чаралар Балтач муниципаль районы бюджетында яисә муниципаль дәрәҗәдәге программаларда һәм проектларда каралган чаралар составында карала.

Шулай итеп, чараларның беренче категориясе буенча мәгълүмат Кушымта нигезендә билгеләнгән вакыт аралыгында хисап формасы буенча тапшырыла. Икенче категория чаралары буенча мәгълүмат Кушымта нигезендә форма буенча чара үткәрүгә рөхсәт алганда тапшырыла, чара үткәрелгәннән соң мәгълүмат шул ук форма буенча, ләкин инде хисап рәвешендә килә.

Мәгълүмат мәгълүмат алу өчен җаваплылык үзәгенә - Балтач муниципаль районы территориясендә “Урманчылык” ДКУнә электрон рәвештә яисә каты күчермәдә тапшырыла. Җаваплылык үзәгенең вазыйфаи затын Кушымтаның формасы буенча исәпкә алу журналы алып бара. Каты күчермәдә һәм электрон рәвештә кергән формалардан мәгълүмат, ________________ мәгълүмат системасын кулланып, мәгълүматлар базасына кертелә, ______________________ мәгълүмат системасын кулланып, аеның 1 нче числосына кадәр Министрлыкка тапшырыла һәм 5 ел дәвамында муниципаль электрон исәпкә алу журналында саклана.

Кушымта

Урманнарны яңадан торгызу һәм урман үстерү чараларына җәлеп ителгән халык саны буенча белешмәләрне мониторинглау формасы

| План | | | | | | | | | Факт | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| № | Чарада катнашучы (оешма/физик зат) | Урманчылык | Адресы | Чараны үткәрү датасы | Мәйдан, га | Утыртылган агачлар саны, мең данә | Төре | Катнашучылар саны | № | Чарада катнашучы (оешма/физик зат) | Урманчылык | Адресы | Чараны үткәрү датасы | Мәйдан, га | Утыртылган агачлар саны, мең данә | Төре | Катнашучылар саны |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Искәрмә: Министрлык адресына тапшырыла торган мәгълүматның (белешмәләрнең) эчтәлеге «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 4 июнендәге 1024 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә билгеләнә.